**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.09.2024 № 1119

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" 23.08.2021 ел, № 863 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетында каралмаган көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау мәсьәләләрендә вазыйфаи зат өчен хокук нормаларын куллануның киң чикләрен яисә нигезсезлеген билгели торган коррупциоген факторларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль Республикасы башкарма комитетының Резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 23.08.2021 ел, № 863 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында нигезләмә".

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 23.08.2021 № 863 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 08.09.2021 № 911, 25.04.2023 № 394, 23.06.2023 № 628 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

16) махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узу өчен гражданнарны (чит ил гражданнарын) җәлеп итү чаралары.».

3. Әлеге карар редакциясендәге Нигезләмәнең гамәлләре 2024 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин